**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Чарлы авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенен Татар Толлысы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Татар Толлысы авылы, Яшел урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 28 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Татар Толлысы авылы, Яшел урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 5 һәм аннан күп күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Татар Толлысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Татар Толлысы авылында чишмәләрне төзекләндерү (будка урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында һәйкәл янына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү);
- Татар Толлысы авылында балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, балалар мәйданчыгына җәяүлеләр юлы ясау (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү).
- ТатарТоллысы авылында юлларны кыш көне кардан чистарту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Чарлы авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру·юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы: Э.Н.Козлов